ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2024 пгт Алексеевское № 580

**Башкарма комитетның 07.05.2024 ел, № 175 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районындагы муниципаль торак фонды составына керүче инвалидлар яшәгән күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми милкәтне һәм шәхси торак фондын тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү һәм чаралар планын раслау турында» карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру чаралары турында» 2016 елның 09 июлендәге 649 номерлы карары, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 06.02.2017 ел, № 21/о «Муниципаль торак фонды составына керүче инвалидлар яшәгән күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне һәм шәхси торак фондын тикшерү буенча муниципаль комиссия тозү һәм эшләү тәртибен раслау турында» боерыгы нигезендә һәм кадрлар алмашынуга бәйле рәвештә

**карар бирәм:**

1. Башкарма комитетның 07.05.2024 ел, № 175 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районындагы муниципаль торак фонды составына керүче инвалидлар яшәгән күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне һәм шәхси торак фондын тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү һәм чаралар планын раслау турында» карарына кушымтаны яңа редакциядә (кушымта) бәян итәргә.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_16.12.2024 ел,_ № _580_
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районындагы муниципаль торак фонды составына керүче инвалидлар яшәгән күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне һәм шәхси торак фондын тикшерү буенча муниципаль комиссия**
**Составы**

| | |
|---|---|
| Хәмзина Е.А.<br><br><br>Язынин Р.С. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе;<br>Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Семина Н.А. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск районындагы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге директоры, комиссия секретаре (килештерү буенча); |
| Солдатова М.А. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килештерү буенча); |
| Фомина Н.А. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Богатов Н.А. | «Идарәче компания» ҖЧҖ директоры (килештерү буенча); |
| Свистунова А.М. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| Фәсахова А.Р. | «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы вазыйфаларын башкаручы (килештерү буенча); |
| Сөләйманов Р.Б. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт, туризм һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча профилактика бүлеге башлыгы; |
| ________________ | Татарстан Республикасы Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасы иҗтимагый оешмасының Алексеевск районы оешмасы рәисе (килештерү буенча); |
| Шәяхмедова А.Р. | Татарстан Республикасы буенча «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фонды филиалының инвалидлар белән эшләү секторының социаль координаторы (килештерү буенча); |

| | |
|---|---|
| Королева Ю.Н. | «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының социаль координаторы (килештерү буенча); |
| Хафизов И.И. | «Мир, доступный для всех» ВОИ СДС эксперты (килештерү буенча); |
| | Алексеевск муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре (килештерү буенча). |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**